ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.04.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1369**

Гавами сервитут билгеләү
турында

Осиново авыл җирлеге Башкарма комитеты (ОГРН 1061673001510, ИНН 1648018049)үтенечнамәсен карап , Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 ст. 1 п., 23 ст. V. 7 бүлегенә, 8 пп. 4 п., «Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 25.10.2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.9 ст. , «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Осиново авылында су объектлары челтәрен реконструкцияләү» проект документациясенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге адресы буенча урнашкан Осиново авыл җирлеге Башкарма комитетының 368,94 кв.м. мәйданлы җир кишәрлегенең 16:20:082701:1253 кадастр номерлы өлешендә линия объекты составында проектлана торган канализация насос станциясен реконструкцияләү максатларында, 49 елга гавами сервитутын билгеләү турындагы үтенечнамәсе нигезендә гавами сервитутын билгеләргә.
2. Гавами сервитут чикләре урнашу урынының кушымта итеп бирелгән график тасвирламасын, 1 нче кушымтада каралганча расларга.
3. Осиново авыл җирлеге Башкарма комитетын (ОГРН 1061673001510, ИНН 1648018049) гавами сервитут хуҗасы итеп билгеләргә.
4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гавами сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясы нигезендә билгеләнә.
5. Осиново авыл җирлеге Башкарма комитетына җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән гавами сервитутны гамәлгә ашыру турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә;
6. Әлеге карар кабул ителгән көннән башлап биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына:

1) әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://zelenodolsk.tatarstan.ru/) сайтында урнаштырырга.
2) гавами сервитутны билгеләү турында карарның күчермәсен хокукларны теркәү органына (Татарстан Республикасы буенча «Роскадастр» җәмәгать-хокукый компаниясе филиалы) җибәрергә, гавами сервитутны билгеләү турында белешмәне Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертүне тәэмин итәргә;
3) Осиново авыл җирлегенең Башкару комитеты адресына әлеге карарның күчермәсен җибәрергә

7. Җир кишәрлегеннән (аның өлешеннән) һәм (яисә) анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектыннан, алардан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.41 ст. 1 п.4 п.п. нигезендә файдалану мөмкин

булмаган яисә гавами сервитут билгеләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә (мондый мөнәсәбәтләр барлыкка килгәндә) сизелерлек кыенлашкан срогы (мондый хәлләр барлыкка килгәндә)– таләп ителми.

8. Осиново авыл җирлегенең Башкару комитетына әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалану төренә туры китереп файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.50 статьясында билгеләнгән срокларда гавами сервитут нигезендә урнаштырылган инженерлык корылмасын, гавами сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң сүтәргә.

9. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

## ГАВАМИ СЕРВИТУТ ЧИКЛӘРЕ УРНАШУЫНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

Объект өчен җирле (муниципаль) әһәмияттәге инженерлык коммуникацияләрен тәэмин итү максатларында гавами сервитут - «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Осиново авылында су кору челтәрен реконструкцияләү».

Мәйданы: 368,94 м2

Объект чикләренең урнашу урыны турында белешмәләр

МСК-16 координаталар системасы, 1 зона

| | Координаталар | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 484892.189 | 1291478.617 |
| 2 | 484892.189 | 1291482.617 |
| 3 | 484885.689 | 1291482.617 |
| 4 | 484885.689 | 1291478.617 |

